**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2015 ел, 25 ноябрь

№ 890

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2004 ел, 16 апрель, 184 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2004 ел, 16 апрель, 184 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 ел, 30 декабрь, 586 нчы; 2006 ел, 6 февраль, 43 нче; 2006 ел, 3 апрель, 146 нчы; 2006 ел, 1 декабрь, 585 нче; 2007 ел, 7 ноябрь, 607 нче; 2007 ел, 26 декабрь, 744 нче; 2009 ел, 14 гыйнвар, 10/1 нче; 2009 ел, 30 гыйнвар, 45 нче; 2010 ел, 6 декабрь, 1002 нче; 2014 ел, 8 июль, 472 нче; 2015 ел, 19 март, 165 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 нче пунктта «Россия Федерациясе,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы пенсионерлары арасыннан булган хезмәткәрләргә шифаханә-курорт дәвалавына юллама, әлеге Тәртип нигезендә яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау

турында» 2011 ел, 14 февраль, 97 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибе нигезендә, аларның сайлавы буенча бирелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\890.docx